РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН
**ГЛАВА**
Агерзинского сельского поселения
Азнакаевского муниципального района

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
Азнакай муниципаль районы
Әгерже авыл җирлеге Советы
**БАШЛЫГЫ**

ул. Г. Ахметова, д. 14а, село Агерзе,
Азнакаевского муниципального района, 423303
Тел. (факс) 8(8-5592) 44-5-21
E-mail: Ager.Azn@tatar.ru

Г. Әхмәтова урамы, 14а, Әгерже авылы
Азнакай муниципаль районы, 423303
Тел. (факс) 8(8-5592) 44-5-21
E-mail: Ager.Azn@tatar.ru

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

«15» ноябрь 2019 ел № 16

Татарстан Республикасы Азнакай
муниципаль районы Әгерже
авыл җирлеге Әгерже
торак пунктында гражданнарның үзарасалым
акчаларын кертү һәм алардан файдалану мәсьәләсе
буенч агражданнар җыенын билгеләү турында

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 06.10.2003 ел № 131-ФЗ Федераль законның 25.1, 56 статьясы, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 28.07.2004 ел № 45-ТРЗ Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы нигезендә, Азнакай муниципаль районы Әгерже авыл җирлеге Уставы белән, **карар чыгарам:**

1.Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы Әгерже авыл җирлеге Әгерже авылында теркәлгән һәм сайлау хокукына ия гражданнар өчен 2019 елның 30 ноябрендә 09 сәгать 00 минутта үзарасалым кертү мәсьәләсе буенча халык җыенының беренче этабын билгеләргә:Яшьләр урамы. Үткәрү урыны: Яшьләр урамы, 23 нче йорт каршында.

2. Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы Әгерже авыл җирлеге Әгерже авылында теркәлгән һәм сайлау хокукына ия гражданнар өчен 2019 елның 30 ноябрендә 11 сәгать 00 минутта үзарасалым кертү мәсьәләсе буенча халык җыенының икенче этабын билгеләргә:Г.Гафиятуллин урамы. Үткәрү урыны: Гафиятуллин урамы, 24 нче йорт каршында.

3. Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы Әгерже авыл җирлеге Әгерже авылында теркәлгән һәм сайлау хокукына ия гражданнар өчен 2019 елның 30 ноябрендә 13 сәгать 00 минутта үзарасалым кертү мәсьәләсе буенча халык җыенының өченче этабын билгеләргә: Г.Ахметова урамы 1 йорттан 24 йортка кадәр, Г.Тукай урамы 1 йорттан 26 йортка кадәр, С.Сайдаш урамы 1 йорттан 24 йортка кадәр, С.Хакима урамы 1 йорттан 48 йортка кадәр. Үткәрү урыны: Әгерже авылы мәдәният йорты.

4. Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы Әгерже авыл җирлеге Әгерже торак пунктында үзарасалым кертү мәсьәләсе буенча халык җыенын оештыручы - Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы Әгерже авыл җирлеге Башкарма комитеты.

5. Гражданнар җыенына чыгарыла торган мәсьәләне расларга:

«Сез 2020 елда Әгерже авыл җирлеге Әгерже торак пункты территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган, 1 Төркем инвалидларыннан, көндезге уку формасында укучы студентлардан тыш, 500 сум күләмендә үзарасалым кертү һәм бу

акчаларны жирле әһәмияткә ия булган түбәндәге сорауларны хәл итүгә юнәлтү белән килешәсезме:

- Әгерҗе авылы, Яшьләр урамы буенча юлларга вак таш җәю (сатып алу, ташу, вак таш җәю, эшләр өчен килешү буенча түләү);;

- Әгерҗе авылы зиратына капка сатып алу һәм кую ; ;

- Әгерҗе авылында («Яңа ел», «Җиңү көне», «Сабантуй», «Халык – ара өлкәннәр көне», "Корбан") бәйрәм чараларын оештыру һәм үткәрү;

- трактор йөртүчесенә хезмәте өчен түләү.

« РИЗА» «КАРШЫ»

6.Әлеге карарны Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат рәсми порталында түбәндәге веб-адрес буенча: http://pravo.tatarstan.ru,Азнакай муниципаль районының рәсми сайтында Татарстан Республикасы Муниципаль берәмлекләре порталында «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә түбәндәге адрес буенча: http://aznakaevo.tatarstan.ru. һәм Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы, Әгерҗе авылы, Г.Ахметова урамы, 1 йорт адресы буенча, Әгерҗе авылы, С.Хаким урамы, урам чатында, Әгерҗе авылы, Г.Гафиятуллина урамы, 10 йорт белән 23а йорты арасында урнашкан Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы Әгерҗе авыл җирлегенең мәгълүмат стендларында урнаштырырга.

7. Әлеге карар ул халыкка игълан ителгән көннән үз көченә керә.

Башлык Н.Н.Хәсәнов